**Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

28 январь 2022 ел № 1

Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 нчы январе 3 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 нчы январендагы 3 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә, 18.1 статьясын түбәндәге нигездә бәян итеп, (Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрендәге 36 номерлы, 2018 елның 22 июнендәге 15 номерлы, 2019 елның 26 февралендәге 3 номерлы, 2019 елның 29 августындагы 16 номерлы, 2021 елның 9 нчы июнендәге 12 номерлы, 2021 елның 23 сентябрендәге 17 номерлы, 2021 елның 23 ноябрендәге 28 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), үзгәрешләр кертергә:

«18. 1. Җир кишәрлекләренең чик күләме:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв. м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең максималь күләме– 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Җирлек башлыгы: Нәбиев И.М.